**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елның 12 августындагы 16-40 номерлы карары**

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны урнаштыру территориаль зонасы (ОД) (55 номерлы контур) һәм катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасы (ОЖ) (39 номерлы контур) чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 20 статьясы нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 3 июлендәге 2046 номерлы «Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны урнаштыру территориаль зонасы (ОД) (55 номерлы контур) һәм катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасы (ОЖ) (39 номерлы контур) чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында Казан шәһәре Думасы карары проектын әзерләү хакында»гы карарын һәм 2025 елның 10 июленнән 2025 елның 24 июленә кадәр уздырылган иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасында, әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә территориаль зона – катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасы (ОЖ) (39 номерлы контур) чикләренә 16:50:060102:18588 кадастр номерлы җир кишәрлеген кертеп, территориаль зона – иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны (ОД) (55 номерлы контур) урнаштыру зонасы чикләрен үзгәртергә;

1.2. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән территориаль зоналарның үзгәрә торган чикләрен Кагыйдәләр составында шәһәр төзелешен зоналаштыруның түбәндәге карталарында чагылдырырга:

- шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы;

- территориаль зоналарның урам-юл челтәре, табигать-рекреация комплексы, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- территориаль зоналарның территориядән югары интенсивлыкта файдалану, шәһәр төзелешендә әһәмияткә ия территорияләр ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: тарихи җирлек ярдәмче зонасы күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- чикләрендә территорияләрне комплекслы үстерү күздә тотыла торган территорияләр картасы;

1.3. Кагыйдәләргә 1 номерлы кушымтаны әлеге карарга 2 номерлы кушымта (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми) нигезендә территориаль зоналар чикләре урнашу урынының график тасвирламасы белән тулыландырырга;


1.4. Кагыйдәләрнең 2 номерлы кушымтасына әлеге карарның 3 номерлы кушымтасы нигезендә территориаль зоналар чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеген (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми) өстәргә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2025 елның 12 августындагы
16-40 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты**




**Шартлы билгеләр**

**ОЖ - 39**

Территориаль зона контурының тәртип номеры

Территориаль зона индексы

**Территориаль зоналар**

| **Төс** | **Индекс** | **Территориаль зона төренең атамасы** |
|---|---|---|
| | ОЖ | Катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасы |
| | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты чиге |

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**